**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 18 ноябрендәге ПУ-1120 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2019 елның 1 февралендәге ПУ-50 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 6 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 17 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 03 июнь
№ 375

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 03 » июнендәге
375 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге (алга таба – Бүлек) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Бүлек «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең төп бурычларын, хокукларын һәм йөкләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында оештырылды.

3. Бүлек Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан оештырыла, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә буйсына.

4. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкилләр турында» 2013 елның 7 маендагы 78-ФЗ номерлы федераль законга, башка федераль законнарга һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актларына, «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

5. Бүлек турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

## II. Бүлекнең төп бурычлары

6. Бүлекнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген оештыру, хокукый, аналитик яктан, документлар белән һәм башка яктан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген эшкуарлык эшчәнлеген үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати яктан һәм аналитика ягыннан тәэмин итү, шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисе өчен эксперт бәяләмәләре, мәгълүмат һәм аналитика материаллары әзерләү.

## III. Бүлекнең төп функцияләре

7. Бүлекнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил йөкләмәләре буенча, эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләрендә бәян ителгән фактларны раслау өчен өстәмә мәгълүмат алуны оештыру;

эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан аларның мөрәҗәгатьләрен карау йомгаклары турында хәбәр итү;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге субъектларын кабул итүне тормышка ашыруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга һәм оешмаларга законнар нигезендә җибәрелгән соратуларын, бәяләмәләрен, мөрәҗәгатьләрен, хатларын карау тәртибе һәм сроклары саклануны мониторинглау;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил адресына җибәрелгән эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләренә анализ ясау һәм аның нигезендә мәгълүмати-белешмә һәм аналитик материаллар, шикаятьләр тудыра торган сәбәпләрне бетерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасында эшлеклелек, инвестиция климаты турында, Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге алып бару шартлары турында мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм анализлауны оештыру,

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил йөкләмәләре буенча аналитик докладлар, мәгълүматлар, белешмәләр, башка материаллар һәм документлар әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең чараларын, очрашуларын, эшлекле сәфәрләрен, аның катнашындагы сөйләшүләрне, киңәшмәләрне планлаштыру, координацияләү, әзерләү һәм аларны уздыруны тәэмин итү, кирәк булганда, әлеге чараларны оештыру-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил аппараты белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру, аның хезмәткәрләре сораткан хисапларны, материаллар һәм белешмәләрне бирү, аларның исәбен алып бару һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең автоматлаштырылган мәгълүмати системасында кирәкле мәгълүматларны урнаштыру;

Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәтенә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил йөкләмәсе буенча массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатында эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләрен тикшерү йомгаклары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге турында кирәкле материалларны бирү;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә эшкуарлык эшчәнлеген алып бару шартларын яхшыртуга юнәлтелгән федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын, башка норматив хокукый актлар эшләү буенча тәкъдимнәр бирү;

үз компетенцияләре чикләрендә алар катнашында узган чаралар йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе беркетмәләре һәм йөкләмәләр исемлекләре проектларын әзерләү;

Бүлек компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышлары текстларын әзерләү;

Бүлек компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларына тәкъдимнәр, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеген үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәләрен үтәү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Бүлек эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил йөкләмәсе буенча шулай ук башка функцияләр дә башкара.

## IV. Бүлекнең хокуклары

8. Үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен Бүлек түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук җәмәгать берләшмәләреннән, оешмалар һәм вазыйфаи затлардан тиешле мәгълүмат һәм материалларны соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карала торган Татарстан Республикасы закон проектларын эшләүдә катнашырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарының тиешле бүлекчәләрендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәҗрибәсен өйрәнергә;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре белән килештереп, Россия Федерациясе законнары нигезендә аерым эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен фәнни һәм мәгариф оешмаларын, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

## V. Бүлекнең хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Бүлек үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Бүлек хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

## VII. Бүлек эшчәнлеген оештыру

11. Бүлекнең структурасы, штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Бүлек эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире җитәкчелек итә, ул Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән килештереп, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

13. Бүлек мөдире:

Бүлек эшен оештыра, Бүлеккә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

Бүлекнең төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенцияләре чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Бүлек хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларны бүлә һәм аларның вазыйфаи регламентларын һәм вазыйфаи инструкцияләрен Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә раслауга бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән килештереп, Бүлек структурасы, штат саны, Бүлек хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм биләгән вазыйфаларыннан азат итү, шулай ук аларны бүләкләү һәм дисциплинар җәзага тарту турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә Бүлек вәкилләрен коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашырга җибәрә.

14. Бүлек мөдире вакытлыча эш урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Бүлек хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән килештереп, Бүлек мөдире тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

---